

Туйкә авылы Азнакай шәһәреннән 5 км ераклыкта, Стәрле елгасы буенда урнашкан.

18 гасырда Азнакай төбәгендә күп кенә татар авылларына нигез салына. Шуларның берсе — Туйкә. Аның барлыкка килү тарихы тирә-як авылларныкына охшаш. Рус хакимиятенең дини, милли һәм икътисадый изүенә түзә алмыйча, Казан өязеннән төбәккә йөзләрчә татар гаиләләре күчеп киләләр. Алар монда авыллар булып урнашалар.

Россия борынгы актлар дәүләт архивында саклаучы III ревизия /1762 ел/ материалларында төбәкнең күп кенә авыллары белән беррәттән, Туйкә дә күрсәтелә. Ревизия кенәгәсен җентекләп өйрәнү төп сорауга ачыклык кертергә ярдәм итә. Документтан күренгәнчә, Туйкә Казан өязеннән күчеп килүчеләр хисабына барлыкка килә. Сословиеләре буенча алар- ясаклы татарлар. Авыл "вновь поселенная деревня Тойкино- Стерли тоже" дип күрсәтелә. Аңа нигез салучылар элек өязнең Җөри юлындагы Туйкә Абдулов сотнясында торганнар.
П_ревизия вакытында /1747 ел/ авыл документта Стәрле дип күрсәтелгән була. Анын хәзерге атамасының килеп чыгышы исә югарыда телгә алынган сотник Туйка Абдулов белән бәйле. Ул монда яшәгән һәм 1758 елны 40 яшендә вафат булган. Авылга нигез салучыларның берсе һәм дәрәҗәле кеше булганлыктан, авыл аның исеме белан атала башлый. Элеккеге атама исә аз кулланыла һәм тора-бара онытыла, бары елга һәм Стәрлетамак авылы /хәзерге Югары һәм Түбән Стәрле/ атамасында сакланып кала.

1859 елда Туйкә- 64 хуҗалыктан торган бер мәчетле авыл. Авылда барлыгы 227 ир-ат һәм 250 хатын-кыз яши.

1884 -1885 елларда Туйкә Азнакай волостенда уртача зурлыктагы авыллардан

санала. Анда 122 хуҗалыкта 335 ир-ат, 323 хатын-кыз яши. Авылда 1 лавка бар. Халык игенчелек, терлекчелек, умартачылык белән шөгыльләнә.

Гасыр ахырына Туйкә беркадәр зурая. 1897 елны анда 154 хуҗалыкта 429 ир-ат һәм 393 хатын-кыз исәпләнә. Авылда мәчет, мәктәп һәм 2 су тегермәне бар.

1900 елда Туйкәдә 2 указлы мулла була- Мөхәммәтшәрип Мусин һәм Минаҗетдин Әхмәткәримов .

Беренче укытучы- Хәйретдин Сәйфетдинов.

1900 елга Туйкәдә һөнәрчелек ( агач эше, тәгәрмәчләр ясау, кирпеч сугу, чабата үрү, итек басу) үсеш ала.

1913 елда төбәк өчен истәлекле вакыйга була: Самара крестьян хужалыгын яхшырту җәмгыяте (Самарское общество улучшения крестьянского хозяйства), яңа оешкан Туйкә кредит ширкәте аша, шушы тирәдәге 44 авылга чөгендер орлыгы тарата. Шушы елдан авыл халкы чөгендерчелек белән дә шөгыльләнә башлый.

1914 елда авыл күп кенә ир-егетләрен герман сугышына озата. Ел ярым эчендә генә авылдан 83 кеше мобилизацияләнә. 1916-1917 елгы чорда тагын 50дән артык кеше хәрби хезмәткә алына.

1917 елга Туйкәдә 201 хуҗалыкта 410 ир-ат һәм 410 хатын-кыз теркәлгән.

1918 елда, 1915 елда салынган 8 почмаклы мәктәп, яна.

1926 елда таш мәктәп салына башлый, ул 1929-1930 уку елына әзер була. Шушы бина - 2007 елга кадәр (оптимизация кысаларында мәктәпне бетергәнче) мәктәп булып тора.

Бүгенге көндә Туйкә авылында 466 кеше яши. Авылда җирле үзидарә, авыл хуҗалыгы җәмгыяте, культура йорты, фельдшер-акушерлык пункты, балалар бакчасы, китапханә, 1 кибет эшләп килә.

Җирлеккә шулай ук Камышлы Күл (53 кеше яши) һәм Карамалы-Елга (49 кеше яши) авыллары да керә. Бу авылларга 1930 елларда Туйкә авылыннан күчеп китүчеләр нигез салган.

Җирлек халкының төп шөгыле- кырчылык, терлекчелек, күп өлеше- нефть сәнәгатендә эшли.